ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.11.2024 Балык Бистәсе штп. №320пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 02.10.2023 №330пи карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм (яисә) алар карамагындагы казна учреждениеләре тарафыннан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторларының бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 13.07.2024 ел, №177-ФЗ Федераль закон нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 02.10.2023 №330пи карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм (яисә) алар карамагындагы казна учреждениеләре тарафыннан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторларының бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 пунктның б пунктчасының 6 абзацында «тапшыру» сүзләреннән соң «түләнергә тиешле сумманы исәпләү көненнән дә соңга калмыйча» сүзләрен өстәргә.;

1.2. түбәндәге эчтәлекле 7 абзац өстәргә:

"Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләр нигезендә эшләнгән бюджетка түләүләр, пенялар һәм алар буенча штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру регламентын билгеләү".

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы” нда һәм Татарстан Республикасы Балык

Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Д.А. Сатдинов